ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

15.07.2020　　　　№ 485

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 февралендәге 68 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Нурлат муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 11.02.2020 ел, № 68 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2020 елның 11 февралендәге 68 номерлы карар преамбуласында: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карары белән (2019 елның 12 июлендәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) сүзтезмәсен түбәндәге сүзтезмәгә алыштырырга: «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче　　　　Л.Н. Маняпов